**Мингазова Резиля Абузаровна,**
*к. филол. н., преподаватель кафедры историко-филологических дисциплин, ГАПОУ «Набережночелнинский педагогический колледж» г.Набережные Челны, Татарстан*
*e-mail: kamiloi@mai.ru*

УДК 82.512.145

# САДРИ ҖӘЛӘЛНЕҢ «ДИМ БУЕНДА» ПОВЕСТЕНДА РОМАНТИК МОТИВЛАР

# РОМАНТИЧЕСКИЕ МОТИВЫ В ПОВЕСТИ САДРИ ДЖАЛЯЛА «НА БЕРЕГУ ДЕМЫ»

# THE ROMANTIC MOTIVES IN SADRI JALAL'S STORY «ON THE DEM – RIVER'S BANK»

**Аннотация.** В статье автор уделяет внимание мотивам романтической любви в повести известного татарского прозаика, публициста, критика Садри Джаляла «На берегу Демы». Любовь Рустама и Фариды воспринимается в романтическом духе, словно спущенное свыше великое чувство. Описывая их платоническую любовь, С. Джалял использовал ряд романтических приемов: написание писем, прием сновидений, образы природы-сада.

Несмотря на то, что любовь героев заканчивается трагически, в произведении утверждается идея о том, что любовь – вечна.

**Ключевые слова:** романтические традиции, культ любви, культ природы, культ романтической музыки, образ романтического сада, мотив сновидений.

**Abstract.** In article the author concerns the romantic love's motives in famous Tatar writer, essayist, critic Sadri Jalal's story «On the Dem –river's bank».

Rustem and Fatima's love is received seen in the romantic ethos, like a great feeling. S. Jalal used a number of romantic techniques describing their platonic love: writing letters, taking dreams, images of nature-garden.

Despite the fact that the heroes' love ends tragically, the Author approves the idea that love is forever.

**Keywords:** romantic tradition, the cult of love, the cult of nature, the cult of romantic music, the image of a romantic garden, the dream motive.

XX йөзнең унынчы елларында кешенең рухи дөньясын, көнелендәге эчке каршылыклар көрәшен ачып бирүдә әдипләр романтизм иҗат ысулына мөрәҗәгать иткәннәр.

Күренекле прозаик, публицист, тәнкыйтьче һәм мөгаллим Садри Җәләлнең (1891-1943) бердәнбер күләмле әсәре «Дим буенда» повесте да искәрмә түгел, ул лирик-романтик рухта язылган.

Әсәрдә сурәтләнгән вакыйгаларда XIX гасыр ахырында гөрләп яшәгән Исхак морза нәселенең акрынлап, тормыш сәхнәсеннән китү тарихы сурәтләнгән. Бу гаиләне С. Җәләл яхшы белгән булса кирәк, чөнки Учительская школада укыганда, ул бер сабакташы, «чабаталы мирза» улы белән яхшы дус була, хәтта берничә тапкыр җәйге ялын Башкортстанда, аларның Дим буендагы утарында үткәрә.

Повесть каһарманнары – Рөстәм, Касыйм, Кәримә – Исхак морза нәселеннән чыккан яшьләр. Ятимә кыз Фәридә дә сигез яшеннән Исхак мирза гаиләсендә тәрбияләнгән. Автор өчен һәр герой-персонаж үзенең асылы, физик үзенчәлеге, калебе белән – табигать баласы. Язучы С. Җәләл бу повестенда шәрекъ романтизмыннан ук башлангыч алган «табигать балалары» темасын көнбатыш һәм рус әдәбияты традицияләре рухында үстереп, табигый инсан концепциясенә мөнәсәбәттә, Рөстәм белән Фәридәнең аянычлы мәхәббәтен сурәтли.

Рөстәм үз дөньясына чумган ялгызак герой. «Ул үз галәмендә, үзенең кадерле уйлары белән ялгыз гына яши һәм бөтен нәрсәсен эчендә генә сакларга белә» [1; 19]. Ул бик горур, милли үзаңы да көчле: төрки бабаларыбыз турында күп китаплар укыган, аларны вәхши халык дип санаучылар һәм Чыңгыз ханның тарихта ролен танымаучылар белән бәхәскә керергә дә күп сорамый. Аны нәкъ менә шул сыйфатлары өчен иптәшләре «степьтан килгән Чыңгыз баласы» дип йөртәләр.

Фәридә дә Рөстәм кебек хыялый, үз хәятендә яшәүче кыз. Ул, романтик героиняларга хас булганча, озын-озын шәрык әкиятләрен тыңларга ярата, еш романтик төшләр күрә. Аларда ул А.С. Пушкинның «Бакчасарай фонтаны» нда тасвир кылынган маҗаралар, Зариманең Гәрәй ханга булган мәхәббәт вакыйгалары белән саташа.

Әмма Фәридәне башкалардан аеручы төп сыйфат – аның бөтен көче белән музыкага бирелүендә. Рояль

аңа дөньяда иң якын кешесе булып күренә. Фәридә рояльдә уйнаганда, Бетховенның моңлы көйләре белән үзенең Рөстәм турындагы уйлары арасында әллә нинди якынлык сизеп, үзенә бертөрле хозур, сәмави шатлык алса, Рөстәм дә Фәридә уйнавыннан әллә нинди бер елау, кара көчтән өзелеп-өзелеп зарлану, зарыгулар, кемгәдер ялынуларын ишеткән кебек була. Шул рәвешле, романтик музыка яшьләрнең арадашчысына, күңел сердәшенә әверелә.

Әсәрдә Рөстәм белән Фәридә бер-берсен яшерен, кыюсыз мәхәббәт белән яраталар, сөюләрен вакытында аңлата алмау кайгысыннан төшенкелеккә биреләләр, тирән газап чигәләр. Фәриданең бу яшерен һәм газаплы сөюдән авыруы көчәя: ул саргая, балавыз шәм төсле ябыга, ара-тирә йөткергәли, көннән-көн кибә, ахыр чиктә, мәхәббәт корбаны булып, якты дөньядан да китеп бара. Романтик С. Җәләлдә без тәкъдирнең хәлиткеч роль уйнавын һәм тәкъдиргә ышануны раслаучы «Хак ни язса, безгә шул булыр...» кебек эчтәлектәге тәкъбирләр белән еш очрашабыз.

Әсәрдә мәхәббәт белән тыгыз бәйле романтик мотивларның берсе – табигать. Гашыйк парларның күңел халәтенә мөнәсәбәттә Дим буе табигате төрле фасылларда сурәтләнгән. Яшьләрнең серле мәхәббәте нәкъ менә яз башында бөреләнеп, җәен, хыялларында чәчәк атса да, көз аенда аларның кыюсызлыгына, мәхәббәтләрен аңлаша алмауларына күктәге йолдызлар да, гомумән, бөтен табигать көлеп карый төсле.

Әсәрдә гашыйк парларның мәхәббәт мөнәсәбәтләрен яктыртуда шулай ук романтик бакча да мөһим роль уйный. Бу могҗизалы бакчада, күрәбез, бар нәрсә дә инсанның күңел кичерешләренә буйсынган: музыка, сайрар кошлар моңы, серле чәчәкләр, күктәге йолдызлар... Гашыйкларның беренче, үзара калып очрашуларына да иң әүвәл бакча шаһит. Алга таба, Рөстәм белән Фәридә еш бакчада йөриләр, аның сихри матурлыгына сокланалар.

Шулай итеп, повестьта Дим буеның гүзәл табигате һәм романтик бакча каһарманнарның психологик халәтләренә янәшә итеп, аларның кәеф-кичерешләренең мөһим компоненты буларак бирелә, әсәрнең сәнгати-эстетик яңгырашын тәэмин итә. Табигать тасвирлары ярдәмендә повестьта романтик атмосфера да тудырыла, геройларның эчке дөньялары да ачыла. Күрәбез, табигать культының «табигый кеше» мәсьәләсе белән тыгыз үрелеп бирелеше повестьта мәхәббәт культының сәнгати чагылышынраслау өчен мөһим алшарт булып тора.

С. Җәләлнең «Дим буенда» повестенда мәхәббәт культы белән бәйле тагын бер мотив – төш күрү мотивы. Беләбез, романтик язучыларны төшләр үзләренең психологик хасиятләреннән бигрәк, укучыга тәэсир итү дәрәҗәсе, төштәге һәм өндәге вакыйгаларның рас килүе белән җәлеп итәләр. Повестьта иң күп төш күрүче – Фәридә. Алда искәрткәнчә, ул үзенең гашыйк булуын төшендә А. Пушкинның романтик каһарманы Заримәдән ишетеп, аңлап ала, төшендә үзенә мәхәббәт дөньясын ача, аерылышу сагышын тоя, өметсез киләчәген күрә.

Әсәрдә Рөстәмнең романтик төшләренә дә күп урын бирелгән. Тормышта үзенең нинди хаталар ясавын, Фәридәне хәсрәткә салуларын ул төшендә аңлап уяна. Әлеге төш Рөстәмнең бар дөньясын үзгәртә, вөҗданын газаплый. Ул саташа башлый, төшләрендә Фәриданең ачы тавыш белән елаганын, өзелеп-өзелеп үзенә чакырганын ишеткән төсле була. Нәтиҗәдә, бу еш кабатланган төшләр Рөстәмне рухи катарсиска китерә: ул рухы, милләте һәм дине белән үзенә ят булган Сараны Киевкә озатып җибәрә һәм Фәридәне эзләргә Кырымга чыгып китә. Әмма соң була... Фәридә урынына Рөстәм аның каберен генә күрә.

Кич белән ул «Хан сарае» дип йөртелгән бакчага килә, скрипкачы уйнавында Кырым татарларының озын һәм бик моңлы көен тыңлый һәм, кайгысыннан, шул скрипка моңы белән бергә елый, сызлана башлый. Аннары ул мәзиннең моңлы итеп азан әйткәнен ишетә: «Аның тавышы музыкадан да ягымлы, сөйкемле тоела, ул бөтен тамыр буенча йөгерә» [1; б. 92]. Рөстәмнең күңеле тынычлана төшә, мәчеткә кереп намаз укыйсы, бөтен якыннары, бар инсаният өчен саф калеб белән дога әйтәсе, авылына кайтып, халыкка ярдәмгә ашыгасы килә.

Әсәрнең идеясенә тирән фәлсәфә салынган. Рөстәмнең Фәридә кабере янында әйткән «Шулай ук без бары үләр өчен генә яратылган микәнни инде?!» дигән юлларда яшәешне фани һәм бакый дөнья баскычларына куеп, экзистенциаль рухта сызлану, тереклек итүнең барыбер үлем белән очлануын тану һәм аның белән килешергә мәҗбүр булу хакыйкате ята.

Романтик әдәбият кануннары буенча бакый дөнья гына яшьләрнең бергә булуларын тәэмин итәчәк, бары тик анда гына аларның җаннары пантеистларча бергә кушылачак. Рөстәм белән Фәриданең дә бакыйлыкта бергә булачакларына шик юк.

Автор романтик мәхәббәт фәлсәфәсен ике гашыйк фаҗигасе мисалында гомумкешелек мәсьәләсе югарылыгына күтәргән. Фәридә белән Рөстәмнең романтик өзгәләнүләрендә шул чор яшьләренең изелгән, авыр рухи халәте чагылган. Ә хыял-омтылышларында исә аларның эстетик идеаллары, киләчәккә юнәлгән изге өметләре сурәтләнгән.

**Әдәбият**


1. Җәләл С. Дим буенда: повесть, хикәяләр. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1991. – 256 б.
2. Хәзерге татар прозасы. Беренче җыентык . – Казан: ТаРИХ, 2003. – Б.5-16.
3. Хәзерге татар прозасы. Икенче җыентык . – Казан: ТаРИХ, 2005. – Б.5-16.